**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Алпар авыл җирлеге башкарма комитеты карары**

**2014 елның 3 феврале** **11а №**

Иске Алпар авыл җирлеге территориясендә җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру урыннарын билгеләү турында

2004 елның 19 июнендәге «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 54-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы һәм 2012 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыруга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы нигезендә Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Алпар авыл җирлеге территориясендә, кушымта нигезендә, җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар уздыру өчен даими урынны билгеләргә.

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының
Иске Алпар авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: Р.К.Шайхутдинов

Әлки муниципаль районының
Иске Алпар авыл җирлеге
башкарма комитетының 2014
елның 3 февралендәге 11а
номерлы карарына кушымта

**Иске Алпар авыл җирлеге территориясендә җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре, пикетлар уздыру өчен урын**

| № № т/б | Муниципаль берәмлек исеме . | махсус билгеләнгән урын адресы | Махсус билгеләнгән урынны тасвирлау |
|---|---|---|---|
| 1. | Иске Алпар авыл җирлеге | Татарстан Республикасы,<br>Иске Алпар ав.<br>Төньяк ур., 29 й. | Төньяк урам буенча 29 йорт янындагы парк территориясе |